| ГЛАВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ ВЕТЕРИНАРИИ КАБИНЕТА МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫНЫҢ БАШ ВЕТЕРИНАРИЯ ИДАРӘСЕ |
|---|---|---|

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

07.08.2015 Казан ш. № 342-п

Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә, “Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында” 16.06.2006, № 310 һәм “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (бу Боерыкка кушымта итеп бирелә) (алга таба – Регламент) расларга.

2. Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре начальникларына, Татарстан Республикасында этләрен теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләренә тайпылышсыз таянып эш итәргә.

3. Ветеринария эшен оештыру бүлеге начальнигы И.Г.Сөләймановка Регламентны Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе сайтына “Дәүләт хезмәтләре күрсәтү” бүлегенең “Административ регламентлар” бүлекчәсенә урнаштырырга.

4. Хокук бүлеге начальнигы А.А.Исмәгыйловка бу Боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми урнаштыруга җибәрүне тәэмин итәргә.

5. Бу Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе начальнигы урынбасары А.Р.Гәрәевка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының Баш
ветеринария идарәсе начальнигы А.Г.Хисаметдинов

Татарстан Республикасы Министрлар
Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең
07.08.2015 ел, № 342-п белән расланды

Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Регламент Татарстан Республикасында Этләрне теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте күрсәтү) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең алучылар: этләр хуҗалары – этләрне торакта, хезмәт бүлмәсе һәм махсус бүлмәләрдә, шулай ук бу максат өчен махсус бирелгән урыннарда асраучы гражданнар һәм юридик затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү эт хуҗасының яшәү яки булу урыны буенча ведомство карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре (алга таба – ГБУ ГГВО һәм РГВО) аша хәл ителә.

1.3.1. Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән тыш, көн саен, дүшәмбе – җомга 8.00 дән 17.00 сәгатькәчә, төшке аш вакыты – 12.00 дән 13.00 сәгатькәчә.
Керү – пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. Ветеринария идарәсенең Интернет-мәгълүмат телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – “Интернет” челтәре) рәсми сайты адресы: http:// guv.tatar.ru.

1.3.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) түбәндәге мәгълүматлардан торган, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мәгълүмати стендлар аша:

– ведомство карамагындагы ГБУ ГГВО һәм РГВО аша Ветеринария идарәсе тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы;

– дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе тасвирламасы;

– дәүләт хезмәте күрсәтүнең срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмага мөрәҗәгать итү зарурилыгыннан чыгып, Россия Федерациясе законы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы;

– дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләр күрсәтү өчен законнар яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алуның ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе;

– дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге;

– Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО эш вакыты турында, Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО белгечләре тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә гаризаларны кабул итү графигы турында мәгълүмат;

– дәүләт хезмәте күрсәтү барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә хокуклары турында дәүләт хезмәте алучыларга мәгълүмат;

– дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры җайга салучы норматив-хокукый актлар исемлеге. Норматив-хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастыру чыганакларын күрсәтеп.

2) “Интернет” челтәре аша:

Ветеринария идарәсенең рәсми сайтында (http:// guv.tatar.ru.);

Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында (http:// uslugi.tatarstan.ru/);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Ветеринария идарәсенә, ГБУ ГГВО һәм РГВО телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Ветеринария идарәсенә, ГБУ ГГВО һәм РГВО язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Ветеринария идарәсенең рәсми сайтына һәм ГБУ ГГВО һәм РГВО бүлмәләрендәге мәгълүмати стендларга урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте этләрне карау өчен китергәндә турыдан-туры күрсәтелә.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге законнар һәм норматив-хокукый актлар нигезендә хәл ителә:

“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – №210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Электрон имза турында” 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” 7 май, 2012 ел, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – № 601 Указ) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 07.05.2012, № 19, 2338 ст.);

“Татарстан Республикасында йорт хайваннарын асрауның аерым мәсьәләләре турында” 7 март, 2014 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы законы (алга таба – № 16 ТРЗ ТР Законы) (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2014, № 3, 206 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентлары системасын эшләү турында” 16.06.2006 ел, № 310 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, № 26, 12.07.2006 ел, № 0647 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 880 ТР МК карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, №46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе мәсьәләләре” 10.03.2012 ел, № 202 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 202 ТР МК карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 24.04.2012, № 31, 0965 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасында Этләрне теркәү тәртибен һәм Куркыныч белән янаучы этләр токымнары исемлеген раслау турында” 05.05.2014 ел, № 298 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 298 ТР МК карар) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 27.05.2014, № 39, 1218 ст., кертелгән үзгәрешләрдән чыгып).

1.6. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

– техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелеп, документка (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) кертелгән мәгълүматларның мәгълүматлар кертүгә нигез итеп алынган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (сүзнең мәгънәсе бозылу, грамматик хата яки арифметик хата яисә шуңа охшаш башка хата);

– бу Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) төшенчәсе № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтү тутында мөрәҗәгать итүченең запросын аңлата. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә гаризаның тәкъдим ителә торган формасы бу Регламентка № 2 кушымтада китерелгән;

– дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгатьләр итүчеләрдән документлар кабул итеп алу һәм бирү, мөрәҗәгать итүчеләргә консультация бирү тәрәзәсе.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләпләр атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1.Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасында этләрне теркәү | № 16-ТРЗ ТР Законының 8 ст.,<br>№ 298 ТР МК карары |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият | Ведомство карамагындагы район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре | № 16-ТРЗ ТР Законының 4 ст. 2 өлеше,<br>№ 298 ТР МК карарының 5 п, № 202 |

| | | |
|---|---|---|
| органы атамасы | аша Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе | ТР МК карарының 3.3.22 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау | Мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык бирү (этне теркәү турында таныклыкны алыштыру, таныклык дубликатын бирү, этне теркәү учетыннан алу) яки таныклык бирүдән баш тарту | № 16-ТРЗ ТР Законының 8 ст. 2 өлеше, № 298 ТР МК карарының 13 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурилыгыннан чыгып, Россия Федерациясе законы нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы | Этне теркәү буенча дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне, гаризаны кабул итү һәм теркәүдән соң 2 сәгатьтән артмаган вакыт эчендә күрсәтелә | № 16-ТРЗ ТР Законының 8 ст.,<br>№ 298 ТР МК карарының 12.18.22, 26 пп. |
| 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле кирәкле документларның тулы исемлеге | Этне теркәү турында гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затның дәүләт теркәвенә алынуы турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда);<br>эттә элегрәк эшләнгән тәңгәлләштерү чараларының булуы турында мәгълүмат | № 298 ТР МК карарыеың 11 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | (булганда);<br>эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат (булганда);<br>эт баласына метрика яки эткә шәҗәрә күчермәсе (булганда);<br>этнең фотосурәте (эт хуҗасының теләгенә карап). | № 298 ТР МК карарының 17п. |
| | Этне теркәү турында таныклык дубликаты бирелү өчен гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда);<br>этне теркәү турында яраксызга чыккан таныклык (булганда). | № 298 ТР МК карарының 21 п. |
| | Этне теркәү турында таныклыкны алыштыру өчен гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен); | |

| | | |
|---|---|---|
| | мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда).<br><br>Этне теркәү учетыннан алу өчен гаризага түбәндәге документлар кушып бирелә:<br>эт хуҗасының паспорты күчермәсе (гражданин өчен) яки юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе (юридик зат өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – физик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаган документ (гражданин өчен);<br>мөрәҗәгать итүченең эт хуҗасы – юридик зат исеменнән эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документ (юридик затлар өчен);<br>эткә мөлкәт хокукы яки башка хокукның булуын раслаучы документ (булганда). | № 298 ТР МК карарының 25 п. |
| 2.6.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булып, мөрәҗәгать итүче тапшыруга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз | Зарурилык юк | |

| | | |
|---|---|---|
| карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив-хокукый актларда күздә тотылган очракларда килештерергә тиешле (бу эшне дәүләт хезмәте күрсәтүче башкарма хакимият органы хәл итә) дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур подразделениеләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне килештерү таләп ителми | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | Документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләр булып тора:<br>бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тулысынча тапшырмау;<br>бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны моңа вәкаләте булмаган зат тарафыннан тапшыру;<br>дөрес булмаган (ялган) мәгълүматлардан торган документлар һәм гамәлдә булу срогы чыккан документлар тапшыру. | |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки аннан баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр:<br>ике ае тулмаган этне дәүләт теркәвенә китерү;<br>этне тикшерүгә бирмәү. | № 298 ТР МК карарының 9, 10 пп. |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә.<br>Этне теркәгәндә ветеринария һхезмәтләре күрсәтелгән очракта (өстәмә ветеринария хезмәтләре күрсәтү), аларга | № 298 ТР МК карарының 21 п.<br>№ 298 ТР МК карарының 7 п.<br><br><br>№ 298 ТР МК карарының 8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | түләү алына, аның күләме Ветеринария идарәсе тарафыннан билгеләнеп, ГБУ ГГВО һәм РГВО локаль акты нигезендә раслана | |
| 2.11.Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булып торган хезмәтләргә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны кертеп | Кирәкле һәм мәҗбүри булып торучы хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12.Дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос тапшырганда һәм мондый хезмәт күрсәтүләрнең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы | Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте алуга мөрәҗәгать иткәндә чиратта көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алучыларның аерым категорияләренә чират билгеләнмәгән. | № 601 Указының 1 п. |
| 2.13.Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросын теркәү срогы | Гариза алынган көнне | № 298 ТР МК карарының 12 п. |
| 2.14.Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм кабул итү урыннарына, дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматларны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтүне алучыларны кабул итү бу максат өчен махсус бирелеп,<br>этне тикшерү өчен өстәл;<br>тиешле медицина инструментлары;<br>янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар рәсмиләштерү һәм саклау өчен кирәкле мебель;<br>ветеринария препаратларын саклау өчен мебель;<br>мәгълүмати стендлар белән җиһазланган урыннарда хәл ителә. | № 601 Указының 1 п. |
| 2.15. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлек күрсәткечләре булып тора: бүлекнең җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашкан булуы, белгечләрнең тиешле санда булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән | № 880 ТР МК карарының 2.4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| элемтәгә керүе саны, аның дәвамлылыгы; дәүләт хезмәте күрсәтүне дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең читтәге эш урыннарында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып | документлар кабул итеп алу өчен бүлмәләрнең тиешле санда булуы;<br>мәгълүмати стендларда, Интернет челтәрендә, Ветеринария идарәсенең рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:<br>гаризаларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын бозмау;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе срогын бозмау:<br>Ветеринария идарәсе һәм аның карамагындагы ГБУ ГГВО һәм РГВО белгечләре тарафыннан бу Регламентны бозу очракларының (нигезле шикаятьләр булу-булмавы).<br><br>Мөрәҗәгать итүченең Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО вәкаләтле вазыйфаи затлары белән элемтәгә керүенең саны:<br>а) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тапшырганда һәм этне теркәү турында таныклык алганда – күп дигәндә бер тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>б) “Интернет” челтәре аша дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тапшырганда һәм этне теркәү турында таныклык алганда – күп дигәндә ике тапкыр (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Мөрәҗәгать итүче белән элемтәгә кереп эшләүнең дәвамлылыгы – күп дигәндә 15 минут. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүматны сайтта (http://tourism.tatarstan.ru) Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең бердәм порталында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә, күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында алырга мөмкин. | |
| 2.16. Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре. | Мөрәҗәгать итүче № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль законның 21.1 һәм 21.2 статьялары таләпләре нигезендә мөрәҗәгать итүченең электрон имзасы белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендәге гариза һәм документлар күчермәләрен ГБУ ГГВО һәм РГВОга электрон туплагычлардан һәм (яки), “Интернет” челтәрен кертеп гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдалану нигезендә тапшырырга мөмкин. | № 63-ФЗ Федераль законның 2 ст. 11 п., № 210-ФЗ Федераль законның 21.1 ст., 21.2 ст. |

## 3. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны башкару эзлеклелеге һәм сроклары, аларны башкару тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләр) башкару үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләрендә, күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында башкару үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) этне тикшерү;

4) эткә идентификация номеры бирү һәм мөрәҗәгать итүчегә этне теркәү турында таныклык бирү.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләрнең эзлеклелегенең блок-схемасы бу Регламентка № 3 кушымтада китерелә.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче, дәүләт хезмәте алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Ветеринария идарәсенә, ГБУ ГГВО һәм РГВОга шәхсән, телефон аша, почта аша, электрон почта аша, шул исәптән, техник мөмкинлек булганда, Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша һәм (яки) хат белән мөрәҗәгать итә.

Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи затлары, мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгать итү ысулына бәйле рәвештә, шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта аша һәм (яки) Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мөрәҗәгать итүчегә консультация бирә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүне алу өчен кирәкле документларның составы, формасы һәм эчтәлеге ягыннан, һәм мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү ягыннан.

3.3. Мөрәҗәгать итүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яки гариза һәм документларны почта аша (“Интернет” челтәрендә электрон почта аша) җибәргәндә дәүләт хезмәте күрсәтү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе, ышанычлысы аша яки почта аша, бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән кирәкле документлар белән бергә, дәүләт хезмәте күрсәтү турында язмача гариза тапшыра.

Гариза һәм документлар № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (расланган) электрон документлар рәвешендә электрон почта аша җибәрелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны рәсмиләштергәндә күрсәтә: фамилиясен, исемен, атасының исемен, юридик зат атамасын, үзенең почта, электрон адресын һәм җавап алу ысулын.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты түбәндәгеләрдән баш тартуга нигезләрнең булу-булмавын тикшерә:

1) бу Регламентның 2.8 пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән;

2) бу Регламентның 2.9. пунктында күздә тотылган дәүләт хезмәте күрсәтүдән. ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты, бу Регламентның 2.8 һәм 2.9 пунктларында күздә тотылган документлар кабул итүдән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булмаган очракта:

гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәүгә ала;

эткә тикшерү үткәрә;

эткә идентификация номеры бирә һәм “Этләрне теркәү журналы”на (бу Регламентка № 9 кушымта) тиешенчә язып куя;

№ 298 ТР МК карары белән расланган формада этне рәсмиләштерә, теркәү турында таныклык (алга таба – таныклык) бирә һәм “Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы”на (бу Регламентка № 4 кушымта) тиешенчә язып куя.

3.3.1.1. Таныклыкта түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

1) теркәүгә алганда эткә бирелә торган идентификация номеры;

2) эт хуҗасының фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, аны булу урыны яки яшәү урыны буенча теркәү турында, шулай ук фактта яшәү урыны турында мәгълүматлар (эт хуҗасы физик зат булып торса);

3) юридик зат атамасы һәм урнашу урыны (эт хуҗасы юридик зат булып торса);

4) этнең токымы, җенесе, төсе, кушаматы, аерым билгеләре, этнең электрон мәгълүмат туплагычка (микрочип) ия булу-булмавы турында мәгълүматлар;

5) эткә карата үткәрелгән мәҗбүри профилактик ветеринария чаралары турында мәгълүмат;

6) этне асрау өчен бүлмә яки җир кишәрлеге адресы.

Мөрәҗәгать итүчегә таныклык бирү турында мәгълүмат “Этләрне теркәү турында бирелгән мәгълүматлар журналы”на (бу Регламентка № 4 кушымта) кертелә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты, бу Регламентның 2.8 һәм 2.9 пунктларында күздә тотылган документлар кабул итүдән һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга нигезләр булган очракта бер эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) гаризаны теркәүгә яки дәүләт хезмәте күрсәтүгә киртәләрнең булуы турында язмача хәбәр итә, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, һәм документларын кире кайтара.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедура хәл ителә:

шәхсән кабул итүдә – бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза алынган көнне һәм ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи затына этне тикшерүгә тәкъдим иткән көнне;

бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән гариза почта элемтәсе аша яки электрон документлар рәвешендә (Интернет челтәре аша) рәвешендә алынганда – ГБУ ГГВО һәм РГВОга гариза һәм документлар алынган көнне яки ГБУ ГГВО һәм РГВОга гариза һәм документлар эш вакыты тәмамланганнан соң алынган очракта – икенче көнне. Бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар ял яки эш көннәре булмаган бәйрәм көннәрендә электрон документлар рәвешендә алынган очракта – ГБУ ГГВО һәм РГВОның беренче эш көнендә (ял көненнән соң яки эш көне булмаган бәйрәм көненнән соң килүче).

Процедуралар нәтиҗәсе: документларны кабул итү, гаризаны мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында теркәүгә алу, этне тикшерү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык, гаризаны һәм документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында уведомление рәсмиләштереп тапшыру, мөрәҗәгать итүчегә документларын кире кайтару.

3.4. Дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең читтәге эш урынында күрсәтелми.

3.5. Техник хаталарны төзәтү тәртибе

3.5.1. Мөрәҗәгать итүче таныклыкта техник хата җибәрелгәнлеген ачыклаган очракта ГБУ ГГВО һәм РГВОга техник хатаны төзәтү турында гариза (бу Регламентка № 5 кушымта), таныклыкта техник хатаның булуы турында дәлилләгән документлар, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә бирелгән таныклыкның төп нөсхәсе белән, тапшыра.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнар мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи заты таныклыкта техник хата булу фактын раслаган очракта, мөрәҗәгать итүчегә яңа таныклык бирелә.

Бирелгән таныклык турында мәгълүмат “Этне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы”на (бу Регламентка № 4 кушымта) кертелә.

Техник хаталы таныклыкның төп нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарылмый.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

3.6. Элек бирелгән таныклыкны югалту яки аның яраксызга килүе сәбәпле таныклык дубликаты бирелә.

Таныклык дубликаты бирү бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар белән, теркәлгән гариза (бу Регламентка № 6 кушымта) нигезендә, таныклыкны биргән ГБУ ГГВО һәм РГВО тарафыннан хәл ителә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты:

таныклык дубликаты бирү турында гаризаны кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын рәсмиләштереп тапшыра;

таныклык дубликаты бирелүе турында “Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы”на язып куя.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән таныклык дубликатын тапшыра.

Процедура нәтиҗәсе: таныклык дубликатын бирү турында гаризаны кабул итү, теркәү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык дубликатын бирү.

3.7. Этнең хуҗасы алышыну, аның яшәү яки булу урыны үзгәрү, шулай ук бу Регламентның 3.3.1.1 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларның үзгәрүе очрагында этне теркәү турында таныклык алыштырыла.

Таныклыкны алыштыру өчен мөрәҗәгать итүче таныклык биргән ГБУ ГГВО һәм РГВОга этне теркәү турында таныклыкны алыштыру турында гариза (бу Регламентка № 7 кушымта белән мөрәҗәгать итә). Гаризага бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кушып бирелә.

Этнең хуҗасы алышынган очракта этнең яңа хуҗасы әлеге гариза белән мөрәҗәгать итә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты:

таныклыкны алыштыру турындагы гаризаны кабул итә һәм терки;

мөрәҗәгать итүченең таныклыгын рәсмиләштерә һәм алыштыра;

таныклыкны алыштыру турында “Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы”на тиешенчә язып куя.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчегә гаризасында күрсәтелгән ысул белән алыштырылган таныклыкны тапшыра.

Процедура нәтиҗәсе: таныклыкны алыштыру турында гаризаны кабул итү, теркәү, мөрәҗәгать итүчегә таныклык рәсмиләштереп тапшыру.

3.8. Эт үлгән очракта яки аны сукбай хайваннарны вакытлыча тоту пунктына тапшыру очрагында этне теркәүдән алу.

Мөрәҗәгать итүче этне теркәүдән алу өчен таныклык тапшырган ГБУ ГГВО һәм РГВОга этне теркәтү учетыннан алу турында гариза (бу Регламентка № 8 кушымта) белән мөрәҗәгать итә. Гаризага бу Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кушып бирелә.

ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи заты:

этне теркәү учетыннан алу турында гаризаны кабул итә һәм терки;

этне теркәү учетыннан алу турында “Этләрне теркәү журналы” (бу Регламентка № 9 кушымта) тиешенчә язып куя.

Бу пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза теркәлгәннән соң бер эш көне эчендә хәл ителә.

Процедура нәтиҗәсе: этне теркәү учетыннан алу турында гаризаны кабул итү, теркәү, этне теркәү учетыннан алу.

4. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүдә агымдагы контрольлекне Регламент нигезләмәләренең үтәлешенә тикшерү юлы белән, Ветеринария идарәсе начальнигы хәл итә.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә контрольлек итүне Ветеринария идарәсенең вазыйфаи затлары хәл итә. Контрольлек итүче вазыйфаи затларның вәкаләтләре вазыйфаи регламентта билгеләнә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгы һәм сыйфатына контрольлек итү тикшерүләр үткәрү, дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләрдән торучы мөрәҗәгатьләрне тикшерү, карарлар кабул итү һәм мөрәҗәгатькә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешенә контрольлек итү формалары булып тора:

делопроизводство алып бару;

документларны карап тикшерү нәтиҗәләренең закон (бу Регламент) таләпләренә туры килүен;

документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәләрен тапшыру срокларын һәм тапшыру тәртибен үтәү.

Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә хәл ителә) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) була.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта гаепле дип танылган дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан Регламентның үтәлешенә контрольлек итү Ведомство идарәсе һәм аның карамагындагы ГБУ ГГВО һәм РГВО эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге хәбәрдарлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат тапшыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләр) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге нигезендә хәл ителә.

5. Ветеринария идарәсенең, ГБУ ГГВО һәм РГВО, Ветеринария идарәсе, ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затының яки Ветеринария идарәсе дәүләт хезмәткәренең гамәлләренә (гамәл кылмау), шулай ук кабул иткән карарларына судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Дәүләт хезмәте алучылар дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы ГБУ ГГВО һәм РГВО вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмау) ГБУ ГГВО һәм РГВО начальнигына шикаять белдерүгә хокуклы.

ГБУ ГГВО һәм РГВО начальнигы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләр Ветеринария идарәсе начальнигына тапшырыла.

Ветеринария идарәсе начальнигы карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырылырга мөмкин.

5.2. Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән, түбәндәге очракларда, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясе башка норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаганда;

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче ГБУ ГГВО һәм РГВО, шулай ук вазыйфаи заты, хезмәткәрләре дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы

хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.3. Шикаять язмача рәвештә кәгазьдә, шулай ук электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять МФЦ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Дәүләт комитетының рәсми сайты (http://tourism.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (вазыйфалар) күрсәтүнең бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы (http:// uslugi.tatar.ru/) аша җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаятьне карап тикшерү срогы – шикаятьне теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче ГБУ ГГВО һәм РГВО, шулай ук вазыйфаи заты мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яки хаталарны төзәтүдән баш тартканда яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять белдерелгәндә – шикаятьне теркәүгә алганнан соң биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче ГБУ ГГВО һәм РГВО, шулай ук вазыйфаи заты, хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар яки мөрәҗәгать итүче – юридик затның атамасы, урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлар), мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (адреслар) (булганда) һәм почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче ГБУ ГГВО һәм РГВО, шулай ук вазыйфаи затының, хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмау) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче ГБУ ГГВО һәм РГВО, шулай ук вазыйфаи затының, хезмәткәренең карары яки гамәле (гамәл кылмау) белән килешмәвен нигезләгән дәлилләр.

5.6. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслаучы документлар күчермәләре кушып бирелергә мөмкин. Мондый очракта шикаятьтә аңа кушып бирелә торган документлар исемлеге китерелә:

5.7. Шикаятькә шикаятьне тапшырган дәүләт хезмәте күрсәтүне алучы кул куя.

5.8. Бу Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән Министрлык тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышлыкларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтелергә тиеш булмаган акча средстволарын кире кайтару рәвешендә, шулай ук башкача;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

Бу пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карар кабул итү көненнән дә соңга калмыйча, мөрәҗәгать итүчегә язмача һәм, мөрәҗәгать итүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки карап тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләтле вазыйфаи зат материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 1 кушымта

Район һәм шәһәр дәүләт ветеринария берләшмәләре

| Дәүләт учреждениесе атамасы | Почта индексы, адресы | Коды | Телефоны | Эл.почта адресы |
|---|---|---|---|---|
| “Әгерҗе район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422231 ТР Әгерҗе ш., Ленин ур., 90 й. | 85551 | 2-46-29ф | **agryz.vet@tatar.ru** |
| “Азнакай район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423300 ТР Азнакай ш., Профсоюз ур., 6 й. | 85592 | 7-22-29ф | **Nailya.Miftahova@tatar.ru** |
| “Аксубай район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423060 ТР Аксубай ш.т.б., Мазелин ур., 35 й. | 84344 | 2-71-58ф | **aksu-vet@mail.ru** |
| “Актаныш район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423740 ТР Актаныш ав., Промзона ур., 8 й. | 85552 | 3-21-19ф | **akt.vet@tatar.ru** |
| “Алексеевск район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422900 ТР Алексеевск ш.т.б., Чистай ур., 5 й. | 84341 | 2-61-35ф | **Tatyana.Petuhova@tatar.ru** |
| “Әлки район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422870 ТР Базарлы Матак ав., Дорожная ур., 8 й. | 84346 | 2-02-50ф | **alkeevo.vet@rambler.ru** |
| “Әлмәт район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423450 ТР Әлмәт ш., Совет ур., 3 й. | 8553 | 32-81-30 | **Alm.Gvo@tatar.ru** |
| “Апас район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422350 ТР Апас ш.т.б., Совет ур., 5 й. | 84376 | 2-15-63 | **Asiya.Gilmanova@tatar.ru** |
| “Арча район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422002 ТР Ар э.б.,. Комсомол ур., 80 й. | 84366 | 3-10-93ф | **Gazima.Gelfanova@tatar.ru** |
| “Этнә район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422750 ТР Олы Әтнә ав., Совет ур., 1б й. | 84369 | 2-21-27 | **Said.Ahmadullin@tatar.ru** |
| “Баулы район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423931 ТР Баулы ш., Вахитов ур., 10 й. | 85569 | 5-77-38ф | **Marina.Usmanova@tatar.ru** |
| “Балтач район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422250 ТР Балтач ав., Комсомол ур., 44 й. | 84368 | 2-62-57 | **Salyahova.Nuriya@tatar.ru** |
| “Бөгелмә район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423230 ТР Бөгелмә ш., Залаков ур., 2г й | 85594 | 9-11-35 ф | **Tatyana.Mosencova@tatar.ru** |
| “Буа район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422430 ТР Буа ш., Р.Люксембург ур., 83 й. | 84374 | 3-24-04 | **Fanciya.Nigmatullina@tatar.ru** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “Югары Ослан район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422570 ТР Югары Ослан, Чехов ур., 66 й. | 84379 | 2-16-38ф | **w-uslwet@mail.ru** |
| “Биектау район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422701 ТР Биектау ав., Үзәк ур., 4 й. | 84365 | 3-15-09ф | **Alfiya.Zakirova@tatar.ru** |
| “Чүпрәле район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422470 ТР Иске Чүпрәле, Сабантуй м., 14 й. | 84375 | 2-23-77ф | **Guv.Drozhzhanoe@tatar.ru** |
| “Алабуга район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423604 ТР Алабуга, Азина ур., 155 й | 85557 | 7-03-37ф | **Igor.Pochkalin@tatar.ru** |
| “Зәй район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423522 ТР Зәй ш., Толстой, 85 й. | 85558 | 6-60-18ф | **Hurshida.Muhamethano @tatar.ru** |
| “Зеленодол район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422551 ТР Зеленодол ш., Столичная ур., 64 й. | 84371 | 3-76-21ф | **zel.dol.vet@rambler.ru** |
| “Кайбыч район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422330 ТР с. Олы Кайбыч ав., Гыйсмәтуллин ур., 5 й. | 84370 | 2-12-26ф | **Saniya.Gaynullina@tatar.ru** |
| “Кама Тамагы район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422820 ТР Кама Тамагы э.б. , Вахитов ур., 4 й. | 84377 | 2-12-70ф | **Ilgamiya.Mannatova@tatar.ru** |
| “Кукмара район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422110 ТР Кукмара ш.т.б., Толстой ур., 1 й. | 84364 | 2-72-00ф | **Nurisa.Shakirova@tatar.ru** |
| “Лаеш район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422610 ТР Лаеш ш., Урожайная ур., 1 й. | 84378 | 2-70-01ф | **Aniya.Fatyhova@tatar.ru** |
| “Лениногорск район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423250 ТР Лениногорск ш., Колхоз ур., 14 й. | 85595 | 6-17-83ф | **Lvet2008@rambler.ru** |
| “Мамадыш район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422191 ТР Мамадыш ш., Пугачев ур., 25 й. | 85563 | 3-18-35ф | **Ilyas.Gaptrahimov@tatar.ru** |
| “Менделеев район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423650 ТР Менделеев ш., Гунин, 1 й. | 85549 | 2-11-72ф | **Haydar.Hadiullin@tatar.ru** |
| “Минзәлә район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423700 ТР Минзәлә, Пролетарская ур, 60 й. | 85555 | 3-13-05ф | **menzel.vet@mail.ru** |
| “Мөслим район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423970 ТР Мөслим ав., Октябрь ур., 44 й. | 85556 | 2-53-88 | **Gavis.Gilemov@tatar.ru** |
| “Түбән Кама район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423570 ТР Түбән Кама ш., Төзүчеләр б., а/я 27 | 8555 | 30-51-44ф | **Svetlana.Rahimova@tatar.ru** |
| “Яңа Чишмә район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423190 ТР Яңа Чишмә ав., Советская ур., 68 й. | 84348 | 2-25-21ф | **Gulnur.Rizvanova@tatar.ru** |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| “Нурлат район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423040 ТР Нурлат ш., Линейная ур., 38 й. | 84345 | 2-55-30 | **Fanilya.Hasanova@tatar.ru** |
| “Питрәч район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422770 ТР Питрәч э.б., Төзүчеләр ур., 4 й. | 84367 | 3-12-56ф | **Elizaveta.Valiullina@tatar.ru** |
| “Балык Бистәсе район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422650 ТР Балык Бистәсе б., Шәймәрданов ур., 21 й. | 84361 | 2-29-72ф | **vetrs@mail.ru** |
| “Саба район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422060 ТР Байлар Сабасы ш.т.б.,М.Җәлил ур., 2 й. | 84362 | 2-30-93 | **Taslima.Hanova@tatar.ru** |
| “Сарман район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423350 ТР Сарман э.б., Профсоюз ур., 22 й. | 85559 | 2-40-57ф | **sarm_vet@mail.ru** |
| “Спас район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422840 ТР Болгар ш., Ленин ур., 2а й. | 84347 | 3-08-41ф | **Dmitriy.Shishkin@tatar.ru** |
| “Тәтеш район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422370 ТР Тәтеш ш., Ветгородок, 11 А й. | 84373 | 2-81-13 | **Galina.Shemyakova@tatar.ru** |
| “Тукай район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423806 ТР Чаллы ш., ЗЯБ б., Тимерюлчылар тыкрыгы, 7 й. | 8552 | 46-40-61ф | **Tukay.vet@rambler.ru** |
| “Теләче район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422080 РТ Тюлячинский район с. Тюлячи ул. Ленина д.82 | 84360 | 2-10-39ф | **Zuleyha.Habibullina@tatar.ru** |
| “Чирмешән район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423100 ТР Чирмешән районы, Чирмемшән ав., Ярминкә тыкрыгы, 23 й. | 84396 | 2-51-20 | **Gulnur.Sharifullina@tatar.ru** |
| “Чистай район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 422980 ТР Чистай ш., Г.Тукай ур., 84 й. | 84342 | 5-17-10ф | **Dinara.Sayfulina@tatar.ru** |
| “Ютазы район дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423950 ТР Урыссу б., Хлебный тыкрыгы, 1 й. | 85593 | 2-68-62ф | **rgvo_urussu@mail.ru** |
| “Чаллы ш. дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423806 Чаллы ш., ЗЯБ б., Автомобильчеләр тыкрыгы, 8 й. | 8552 | 46-91-41ф | **gosvet-Chelny@mail.ru** |
| “Түбән Кама ш. дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 423577 ТР Түбән Кама ш., Спорт ур., 12в й. | 8555 | 39-47-79 | **Leysan.Gimranova@tatar.ru** |
| “Казан ш. дәүләт ветеринария берләмшәсе” ДБУ | 420073 ТР Казан ш., Шуртыгин, 4 й | 843 | 272-63-92 | **gorvetob@rambler.ru** |

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 2 кушымта

*Тәкъдим ителә торган гариза формасы*

Начальнику ГБУ ГГВО или РГВО

от ________________________
фамилия, имя, отчество заявителя
____________________________

телефон: ___________________

Заявление

Прошу провести клинический осмотр и выдать свидетельство о регистрации собаки


___________________________________________________________
кличка или идентификационный номер собаки
___________________________________________________________
дата рождения, пол, порода.
___________________________________________________________
фамилия, имя, отчество владельца или наименование юридического лица
___________________________________________________________
данные о регистрации по месту пребывания или месту жительства
___________________________________________________________
физического лица (место нахождения юридического лица)
___________________________________________________________
данные о месте фактического проживания физического лица
___________________________________________________________
паспортные данные владельца собаки

Действующий на основании ________________________________________________
(реквизиты документа, подтверждающего полномочия заявителя представлять интересы получателя государственной услуги)

Подпись заявителя
Дата

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 3 кушымта

## Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы



Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 4 кушымта

**Этләрне теркәү турында бирелгән таныклыклар журналы**

| Этнең идентификации номеры | Эт хуҗасының Ф.И.О яки юридик затның атамасы | Эт хуҗасының яки юридик затның фактагы адресы | Этне теркәү турында таныклык бирү датасы | Этне теркәү турында таныклык алу хакында имза |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 5 кушымта

*Тәкъдим ителә торган форма*

Начальнику ГБУ ГГВО или РГВО

от ________________________
Фамилия, имя, отчество заявителя
____________________________

телефон: ___________________

Заявление
об исправлении технической ошибки

Прошу исправить техническую ошибку, допущенную в выданном мне свидетельстве о регистрации собаки.
Данные, которые следует исправить:____________________________________________
______________________________________________________________________________.
Данные в исправленном виде: ___________________________________________________
______________________________________________________________________________.

Приложения к заявлению:
1. Оригинал свидетельства с допущенной технической ошибкой;
2. ________________________

Подпись заявителя
Дата

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 6 кушымта
*Тәкъдим ителә торган форма*

Начальнику ГБУ ГГВО или РГВО

от ___________________________
Фамилия, имя, отчество заявителя
______________________________

телефон: ____________________

Заявление
о выдаче дубликата свидетельства

В связи с утратой (приведением в негодность) свидетельства о регистрации собаки, прошу выдать мне дубликат свидетельства о регистрации собаки.

Приложения к заявлению:
1. ________________________;
2. ________________________.

Действующий на основании ________________________________________________________________
(реквизиты документа, подтверждающего полномочия заявителя представлять интересы получателя государственной услуги)

Подпись заявителя
Дата

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 7 кушымта

*Тәкъдим ителә торган форма*

Начальнику ГБУ ГГВО или РГВО

от ___________________________
Фамилия, имя, отчество заявителя
______________________________

телефон: ____________________

Заявление
о замене свидетельства

В связи смены владельца собаки/изменения места жительства или местонахождения владельца собаки/изменения данных, указанных в свидетельстве о регистрации собаки, прошу заменить выданное мне свидетельство о регистрации собаки.

Приложения к заявлению:
1. _________________________;
2. _________________________.

Действующий на основании ________________________________________________________________________________
(реквизиты документа, подтверждающего полномочия заявителя представлять интересы получателя государственной услуги)

Подпись заявителя
Дата

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 8 кушымта

*Тәкъдим ителә торган форма*

Начальнику ГБУ ГГВО или РГВО

от ___________________________
Фамилия, имя, отчество заявителя
______________________________

телефон: ____________________

Заявление
о снятии собаки с регистрационного учета

В связи со смертью собаки/передачи собаки в пункт временного содержания безнадзорных животных, прошу снять принадлежащую мне собаку с регистрационного учета.

Приложения к заявлению:
1. _________________________;
2. _________________________.

Действующий на основании ___________________________________________________________________
(реквизиты документа, подтверждающего полномочия заявителя представлять интересы получателя государственной услуги)

Подпись заявителя
Дата

Татарстан Республикасында этләрне
теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына № 9 кушымта

**Этләрне теркәү журналы**

| | | Хайванның тасвирламасы | | | | | | | Котыру авыруына каршы вакцинация һ.б. | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| № п\п | Эт хуҗасының ФИО | Этне асрау урыны адресы | Этнең идентификация номеры | Кушаматы | Туу датасы | Җенесе | Токымы | Төсе | Вакцинация, эшкәртү датасы | Вакцина сериясе | Ветеринария табибы имзасы | Башка искәртүләр |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | |